**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының**
**«Татар Димскәе авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче**
**Татар Димскәе авылы торак пунктында гражданнар җыены карары**

**2024 елның 06 декабре,** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татар-дым муниципаль берәмлегенең Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының Татар Димскәе авыл җирлеге" Татар Димскәе авылы торак пунктындагы гражданнар җыены нигезендә

карар кылды:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Татар Димскәе авыл җирлеге» Татар Димскәе авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, тыл хезмәтчәннәреннән махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын, күп балалы гаиләләрдән тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

Торак пункт территориясен төзекләндерү, атап әйткәндә:

- Татар Димскәе авылына керү юлында Стелла ясау һәм урнаштыру;
- Татар Димскәе авылы Совет урамындагы Геройлар аллеясын төзекләндерү (яктырту, тротуар плитәсе сатып алу һәм урнаштыру һ.б.).

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**

**Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районының**
**«Татар Димскәе авыл җирлеге "**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **Л. А. Хәбирова**